*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 42**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) өчпочмак
   ә) бавырсак
   б) кыстыбый
   в) чөгендер

2. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) төлке
   ә) яңгыр
   б) унбер
   в) чөнки

3. Омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Безнең бакчада кашкарый һәм миләүшә чәчәкләре үсә. – Безгә кунакка Миләүшә апа килде.*
   а) саф лексик
   ә) омоформалар
   б) омофоннар
   в) омографлар

4. Диалекталь сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) баннер
   ә) патша
   б) җиләк
   в) җаулык

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) көзге
   ә) бүген
   б) бүлмә
   в) кызык

6. Җөмләдәге санның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Песнәкләрнең уннан тугызы суыктан түгел, ачлыктан үлә.* (Календарьдан).

а) микъдар
ә) тәртип
б) чама
в) бүлем

7. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) барган
ә) барды
б) барыр
в) барачак

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Лачын кошка һава кадерле.* (Мәкаль).

а) лачын
ә) кошка
б) һава
в) кадерле

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[м], [н] [ ___ ] – борын тартыклары. Сүзлекләр төзү турындагы фән ____________ дип атала. ____________ кушымчалар сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртәләр һәм яңа сүз ясыйлар. ____________ саны предметларның яисә затларның тигез өлешләргә бүленүен белдерә. Предметның кемнеке икәнен, кайсы затка караганын белдерә торган алмашлыклар ____________ алмашлыклары дип атала.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(12 балл)**

*Некоторые птицы совершают свои перелёты в одиночку. Но большинство птиц мигрирует в составе стаи.*

*В зависимости от привычного образа жизни перелётные птицы обычно летят либо ночью, либо днём. Но некоторые их виды способны лететь днями и ночами без перерыва. Они засыпают в полёте и изредка отвлекаются на поиск пищи.*

*Перелётные птицы возвращаются точно к своим гнёздам.*

2. Кошлар тормышы турында тагын ниләр беләсез? Шул хакта 9 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(9 балл)**